КОНКУРС
Легендарные бренды «ТАТМЕДИА»

# УЧАСТНИК
# Филиал АО ТАТМЕДИА
# «Редакция газеты «Арча хәбәрләре»

**(«Арский вестник»)**

**Номинация**
**«Газета»**

# Тарихта без эзлебез

2015 елның октябрендә Арча район газетасы чыга башлауга 85 ел тула.

1930 елның 15 июлендә ВКП(б) Үзәк Комитеты эре үзәкләрдә һәм районнарда газеталар оештыру турында директива кабул итә. Матбугат эшләре буенча Союз комитеты Татарстан Республикасында 5 район газетасы чыгаруны билгеле. Шулар арасында Арча районы да бар, анда русча–татарча газеталар чыгару билгеләнә (1) [1].



Копия.

Представительство ТССР при Президиуме ВЦИК.
26 июля 1930 г. исх.№ 16160.

СОВНАРКОМ ТССР

копия: Татиздат.

г. Казань.

Согласно срочной директивы ЦК ВКПб от 15/VII об организации газет в крупных центрах и районах, Союзный Комитет по делам печати ориентировочно намечает в районах Татреспублики 5 газет, а именно:

1) Арск - русско-татарск. газету
2) Буинск " "
3) Спасск - русскую газету
4) Наб. Челны - " "
5) Рыбно-Слободская - русско-татарск. газ.

чем Представительство доводит до Вашего сведения.

Зид Представителя ТР при Президиуме ВЦИК
Храповский.

Консультант Раскин.

РНО: За Начканц СНК ТР Кадыршин.

Соңрак ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты Культпромы 1930 елның 1 октябреннән 15 авыл районнары газеталары проектлану турында хәбәр итә. Кайбер районнарда алар элеккеге кантон һәм колхоз газеталары базасында оештырыла, ә Арча районында өр-яңадан чыгару күздә тотыла. Шунда ук, Арча районында, бик үк җиһазландырылмаган типография булуы әйтелә (2).



Список

районных газет и ответ. редакторов.

1. Бугульминская - русская
2. Тумутукская - татарская
3. Бавлинская - татарская, Валеев.
4. Чистопольская - тат. и рус., Муравьев.
5. Мензелинская - Тат., Кадыров
6. Елабужская - рус. Евстафьев
7. Челнинская - тат., Кончурин
8. Алексеевская - русская, Елисеев
9. Спасская- - " - Каменская, 1920г., елу:
10. Тетюшская - " -
11. Буинская - татар. Кабиров.
12. Арская - татар. Исхаков
13. Кукморская - тат., Карамуллин
14. Аксубаевская - чув., Яковлев
15. Сабинская - тат., Маликов

Арча район газетасының беренче редакторы итеп Фатыйх Исхаков билгеләнә. Район газетасы чыгаруга әзерлек барган көннәрдә “Кызыл Татарстан” газетасының күчмә

редакциясе районга килеп ике ай дәвамында “Колхозга” дигән  листовка чыгара. Беренче район газетасы да шул исем белән чыга башлый.

Кызганычка каршы, Арча район газетасының беренче саны архивларда сакланмаган. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсендә 1932 елның 10 гыйнварында чыккан “Крепим колхозы”  (русча газета) газетасын таба алдык. (3)(4)


КРЕПИМ КОЛХОЗЫ

Орган Арского Райкома ВКП (б) РИК'а и Райпрофсовета.

Выходит раз в пятидневку

№ 2 (7) Воскресенье 10-го января 1932 года ПОДПИСНАЯ ЦЕНА: на год—1 рубль. На 6 мес. — 50 коп. № 2 (7)

ТРЕТЬЕЙ РАЙОННОЙ ПАРТ КОНФЕРЕНЦИИ РАПОРТОВАТЬ О ГОТОВНОСТИ К СЕВУ

Учесть уроки прошлого года в работе М.Т.С

Арскому Райкому ВКП (б) Райисполкому и редакции газет „Колхозга“ и „Крепим Колхозы“

ПОРА ПОКОНЧИТЬ С НЕДООЦЕНКОЙ ПОДГОТОВКИ КАДРОВ М.Т.С.

НАЧАЛСЯ ЗВЕЗДНОЙ ЛЫЖНЫЙ ПРОБЕГ.


KOLXOZÇA

Gazitka jazьlu вəjəse: 1 jьlga . . . . 1 sum 70 tien. 6 ajga . . . . — 85 tien. 3 ajga . . . . — 45 tien.

Adris: Arca, Sovitlar jortь. Tilifon № 16.

Вrəmnəp 3 tien.

№ 1 (96) Pənçeşəmbə 7 nce ǴINVAR 1932 nce Jьl № 1 (96)

III nce rajon partiə konferinsiəsenə cəcygə xəzrlkne təmamlap raportlarь tapşrmagan вrgenə aul sovetьda, вrgenə kolxozda qalmasьn

RAJKOM BJUROSЬNЬŅ 30 NCЬ DEKƏBR QƏRARЬNNAN

AT SBROJ - JAZGЬ CƏCYNE XƏL ITYCE UCASKALARDAN

Sьbrujlar çitşmi

Atlarь jaxşь tərbiələmilər

Joldьz caŋgь савьgь вaşlandь

Texnika kul'turalarь həm msl azьgь cəcy planь вer tzaanda kimetməsen

17 nce gьenvarda bulacaq rajon partiə konferinsiəsenə — kvartal fenplanьnь 40 prosentьn tutьrьrga

Ул вакытта газета ун көнгә бер тапкыр ике битле булып чыккан. Бер елга язылу бәясе – 1 сум, 6 айга – 50 тиен. Газетаның беренче битендә МТС эшен яхшырту турында мәкалә, Утар Аты колхозы әгъзаларының мөрәҗәгате урын алган. Икенче биттә кролик асраучыларга киңәшләр, кар тотуның мөһимлеге, табиб киңәшләре бирелгән.

1937 елда район газетасы “Удар колхоз” исеме белән чыга. 1940 елдан “Яңа тормыш” һәм “Новая жизнь” дип үзгәртелә. 1962 елдан “Коммунизмга”, 1991 елдан бүгенгә кадәр “Арча хәбәрләре” исемнәре белән чыга.

Газетабызның исеме илдәге үзгәрешләр белән бәйле. ВКП(б) Үзәк Комитеты коллективлаштыруның соңгы срогы итеп 1932 елны билгели. Әмма колхозлаштыру хәрәкәте авырлыклар белән бара. 1930 елда чыга башлаган район газетасының “Колхозга” дип аталуы очраклы хәл түгел.

1940 елда район газетасы “Яңа тормыш” дигән исем белән чыга башлый. Ул халыкка хөкүмәт һәм партия сәясәтен җиткерүче, халыкны яңа тормыш төзүгә оештыручы, туплаучы ролен үтәгән.

Сугыш алдыннан район газетасы редакциясе 7 хезмәткәрдән торган.

Бөек Ватан сугышы район халкы һәм шул исәптән редакция коллективы өчен дә зур сынау була. 1940 елда газета редакторы Габделхак Мөхәммәтҗановны Ленинградка партия мәктәбенә укырга җибәрәләр. Ул, шуннан сугышка алына, Бөек Ватан сугышында, Япон сугышында катнашып, 1947 елда кайта, II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә. Пенсиягә чыкканчы район газетасы редакторы урынбасары булып эшләде.

Сугыш елларында газета үз–үзен аямыйча хезмәт куйган, фронтны икмәк, кием–салым һәм башка кирәк–ярак белән тәэмин иткән кешеләр батырлыгын яктырта. Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен дигән лозунг белән эшли. Ул елларда чыккан газета битләрен дулкынланмый уку мөмкин түгел. Редакция 1945 елның 10 маенда чыккан газетаны Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан яңадан бастырып райондашларыбызга таратуны оештыра.

21 ел район газетасы редакторы булган Шакир Гафаров 1941 елда сугышка алына, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә, 1946 елда гына кайта (5) (6).



Да здравствует наша великая сталинская победа!

ПРОЛЕТАРИИ ВСЕХ СТРАН, СОЕДИНЯЙТЕСЬ!

НОВАЯ ЖИЗНЬ

Орган Арского райкома ВКП(б) и районного Совета депутатов трудящихся.

№ 18 (921) | ЧЕТВЕРГ, 10 МАЯ 1945 ГОДА | ЦЕНА 15 КОП.

ВЕЛИКИЕ ЖЕРТВЫ, ПРИНЕСЕННЫЕ НАМИ ВО ИМЯ СВОБОДЫ И НЕЗАВИСИМОСТИ НАШЕЙ РОДИНЫ, НЕИСЧИСЛИМЫЕ ЛИШЕНИЯ И СТРАДАНИЯ, ПЕРЕЖИТЫЕ НАШИМ НАРОДОМ В ХОДЕ ВОЙНЫ, НАПРЯЖЕННЫЙ ТРУД В ТЫЛУ И НА ФРОНТЕ, ОТДАННЫЙ НА АЛТАРЬ ОТЕЧЕСТВА, — НЕ ПРОШЛИ ДАРОМ И УВЕНЧАЛИСЬ ПОЛНОЙ ПОБЕДОЙ НАД ВРАГОМ.

(И. СТАЛИН).

Обращение тов. И. В. Сталина к народу

Товарищи! Соотечественники и соотечественницы!

Наступил великий день победы над Германией. Фашистская Германия, поставленная на колени Красной Армией и войсками наших союзников, признала себя побежденной и об'явила безоговорочную капитуляцию.

7 мая был подписан в городе Реймсе предварительный протокол капитуляции. 8 мая представители немецкого Главнокомандования в присутствии представителей Верховного Командования союзных войск и Верховного Главнокомандования советских войск подписали в Берлине окончательный акт капитуляции, исполнение которого началось с 24 часов 8 мая.

Зная волчью повадку немецких заправил, считающих договора и соглашения пустой бумажкой, мы не имеем основания верить им на слово. Однако сегодня с утра немецкие войска во исполнение акта капитуляции стали в массовом порядке складывать оружие и сдаваться в плен нашим войскам. Это уже не пустая бумажка. Это — действительная капитуляция вооруженных сил Германии. Правда, одна группа немецких войск в районе Чехословакии все еще уклоняется от капитуляции. Но я надеюсь, что Красной Армии удастся привести ее в чувство.

Теперь мы можем с полным основанием заявить, что наступил исторический день окончательного разгрома Германии, день великой победы нашего народа над германским империализмом.

Великие жертвы, принесенные нами во имя свободы и независимости нашей Родины, неисчислимые лишения и страдания, пережитые нашим народом в ходе войны, напряженный труд в тылу и на фронте, отданный на алтарь Отечества, — не прошли даром и увенчались полной победой над врагом. Вековая борьба славянских народов за свое существование и свою независимость окончилась победой над немецкими захватчиками и немецкой тиранией.

Отныне над Европой будет развеваться великое знамя свободы народов и мира между народами.

3 года назад Гитлер всенародно заявил, что в его задачи входит расчленение Советского Союза и отрыв от него Кавказа, Украины, Белоруссии, Прибалтики и других областей. Он прямо заявил: „Мы уничтожим Россию, чтобы она больше никогда не смогла подняться". Это было 3 года назад. Но сумасбродным идеям Гитлера не суждено было сбыться, — ход войны развеял их в прах. На деле получилось нечто прямо противоположное тому, о чем бредили гитлеровцы. Германия разбита наголову. Германские войска капитулируют. Советский Союз торжествует победу, хотя он и не собирается ни расчленять, ни уничтожать Германию.

Товарищи! Великая Отечественная война завершилась нашей полной победой. Период войны в Европе закончился. Начался период мирного развития.

С победой вас, мои дорогие соотечественники и соотечественницы!

**Слава нашей героической Красной Армии, отстоявшей независимость нашей Родины и завоевавшей победу над врагом!**

**Слава нашему великому народу, народу - победителю!**

**Вечная слава героям, павшим в боях с врагом и отдавшим свою жизнь за свободу и счастье нашего народа!**

УКАЗ

Президиума Верховного Совета СССР

ОБ ОБ'ЯВЛЕНИИ 9 МАЯ ПРАЗДНИКОМ ПОБЕДЫ

В ознаменование победоносного завершения Великой Отечественной войны советского народа против немецко-фашистских захватчиков и одержанных исторических побед Красной Армии, увенчавшихся полным разгромом гитлеровской Германии, заявившей о безоговорочной капитуляции, установить, что 9 Мая является днем всенародного торжества — **праздником победы.**

9 мая считать нерабочим днем.

*Председатель Президиума Верховного Совета СССР*

М. КАЛИНИН.

*Секретарь Президиума Верховного Совета СССР*

А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
8 мая 1945 года.

В СОВНАРКОМЕ СССР

В соответствии с Указом Президиума Верховного Совета СССР об об'явлении 9 мая праздником победы Совнарком СССР постановил считать 9 мая 1945 года нерабочим днем.

Совет Народных Комиссаров СССР предложил всем советским государственным учреждениям 9 мая с. г. в день всенародного торжества — **праздник победы** поднять на своих зданиях Государственный Флаг Союза Советских Социалистических Республик

ПРИКАЗ

Верховного Главнокомандующего

по войскам Красной Армии и Военно-Морскому Флоту

8 мая 1945 года в Берлине представителями германского Верховного Командования подписан акт о безоговорочной капитуляции германских вооруженных сил.

Великая Отечественная война, которую вел советский народ против немецко-фашистских захватчиков, победоносно завершена, Германия полностью разгромлена.

Товарищи красноармейцы, краснофлотцы, сержанты, старшины, офицеры армии и флота, генералы, адмиралы и маршалы, поздравляю вас с победоносным завершением Великой Отечественной войны.

В ознаменование полной победы над Германией сегодня, 9 мая, в день победы, в 22 часа столица нашей Родины Москва от имени Родины салютует доблестным войскам Красной Армии, кораблям и частям Военно-Морского Флота, одержавшим эту блестящую победу тридцатью артиллерийскими залпами из 1000 орудий.

Вечная слава героям, павшим в боях за свободу и независимость нашей Родины!

Да здравствуют победоносные Красная Армия и Военно-Морской Флот!

*Верховный Главнокомандующий*
*Маршал Советского Союза*
*И. СТАЛИН.*

9 мая 1945 г.
№ 369.

Габдрахман Кадыйров — 1932–1937
Габделхак Мөхәммәтҗанов —1940–1941
Миннегали Гарифуллин — 1941–1953
Шакир Гафаров — 1950–1971
Ренат Таҗиев — 1971–1980
Тәлгать Мостафин — 1981–1989
Тәлгать Гомәров — 1989–2006
Исрафил Насыйбуллин — 2006 елдан [2].

## Язмышым синдә, Арчам!

Шәхесләр

Төрле чорда редакциядә эшләп, соңыннан җитәкче урыннарны биләгән, республика күләмендә танылган шәхесләребез дә бар. Сәет Хәкимҗанов (1974–1978)–Татарстан Республикасы элемтә министры урынбасары, элемтә техникумы директоры; Фидаил Җәләлиев (1958–1972) – “Татнефтепродукт” акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары, Илфат Фәйзрахманов (1982–1984) – “Безнең гәҗит” редакторы, Хәнәфи Бәдигый (1974–1975) – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Галиәхмәт Шаһиәхмәтов (1980–1982) –Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. “Социалистик Татарстан” газетасы хәбәрчесе, Балтач районы газетасы редакторы Әхәт Фазылҗанов (1962–1968), Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Нәҗип Мадьяров (1960–1965), язучы Дамир Галимов (1956–1961), Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Гайсә Гатауллин (1995–1996), Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Радик Фаизов (1965–2001) күптән вафат инде [4].

**Алар безнең газета турында:**

**Фидаил Җәләлиев (8):**



“1954 елның 15 декабрендә район газетасы редакциясенең ишеген ачып кердем. Кичке мәктәп тәмамлаган 17 яшьлек егетне әдәби хезмәткәр итеп эшкә алдылар. Гомерем буе журналист булуым белән горурланып яшәдем. 51 елга якын хезмәт стажымның 14 елын гына редакциядә үткәрсәм дә, монда барлык калган эшчәнлегемә җитәрлек тормыш тәҗрибәсе алдым”.

**Сәет Хәкимҗанов (9):**



“Коммунизмга” (“Арча хәбәрләре”) газетасында мин җитмешенче елларда эшләдем. Ул минем өчен чын тормыш мәктәбе булды. Аннан соң да миңа Арчада егерме елдан артык эшләргә туры килде. Каләмдәшләрем белән һәрвакыт аралашып яшәдем, ул вакытларны әле дә сагынып яшим, һәр мизгелен хәтердә саклыйм”.

**Хәнәфи Бәдигый (10):**



“Казан дәүләт, педагогика, милли университетларда, консерваториядә доцент, профессор дәрәҗәсендә 35 ел чамасы студентлар укыттым, декан ярдәмчесе, проректор вазыйфаларын башкардым, 150дән артык фәнни хезмәт яздым, 50дән артык әдәби–гыйльми доклад укыдым, бер дистәдән артык китап нәшер иттем, “Казан”, “Мирас” журналларында бүлек мөхәррире, мөхәррир урынбасары вазыйфаларын башкардым, бик күп язмалар бастырдым, шигырьләремә ике дистәдән артык көй иҗат иттем. “Коммунизмга” (“Арча хәбәрләре”) газетасында эшләү тәҗрибәм әдәби иҗатта да, фәнни–педагогик, журналистик эшчәнлектә дә кирәкле һәм файдалы булды” [3].

**Безнең район газетасы турында танылган шәхесләр ни сөйли:**

**Татарстан Республикасы матбугат, телерадиотапшырулар эшләре һәм массакүләм коммуникация чаралары министры Зилә Вәлиева (11):**



“Бүген “Арча хәбәрләре” газетасы тормышыбызның төрле якларын яктыртып баручы күркәм газетага әверелде. Газета милли үзаңны, халкыбызның гореф–гадәтләрен торгызуда аның тарихын, моңын бөек югарылыкка күтәрүдә фидакарьләрчә эшли. Гади авыл кешесе, авыл хуҗалыгы эшчесенең язмышы һәрвакытта игътибарыгыз үзәгендә булуы да, язмаларыгыз аша эш кешесенең дәрәҗәсен күтәрүегез, аңа булган игътибарны арттыруыгыз куандыра”.

**Драматург Туфан Миннуллин (12):**



“Арча төбәге журналистларга, язучыларга бай як. Риман Гыйлемханов көчле, зур журналистларның берсе. Язучы Радик Фәизов шулай ук оста каләм иясе. Гомумән, сез татар теленең сафлыгын саклыйсыз… Район җитәкчеләре газетага кырын карамасыннар, кысалардан чыгарга рөхсәт итсеннәр иде”.

**Район хакимияте башлыгы Илһам Сабиров (13):**



“Арча хәбәрләре” газетасы районыбызның елъязмачысы, заман сулышын халыкка җиткерүче. Газета һәрвакытта да халык белән, үз укучыларына киңәшче һәм дус. Редакциядә таләпчән, белемле, журналист этикасына тап төшермәгән шәхесләр эшләде. Анда хезмәт иткән күренекле кешеләр газета, район тарихына зур хәрефләр белән язылачак” [6].

## Зур бүләкләр сызганып эшкә бирелгәннән килә

“Арча хәбәрләре” газетасы редакциясе хезмәткәрләре элек-электән хезмәт алдынгыларын мактаган, олылаган, ә коллективның хезмәтен бәяләп, зур бүләкләр бирүче булмаган. Матбугат көнендә, юбилей елларында газетаның 1нче саны чыккан октябрь аенда хатлар бүлеге хезмәткәрләре авыл хәбәрчеләре турында язганнар, хезмәтләренә бәя биргәннәр, ә үзләренә карата тыйнаклык күрсәткәннәр. Редакция хезмәткәрләре нинди кыен елларда эшләгән. Авыллардан кайтып кермәгәннәр, кимчелекләрне тәнкыйть утына тотканнар, шикаять хатларын тикшерергә юлга чыгып киткәннәр. Ә сүз яки хәреф хатасы китсә, бюрога чакырганнар.

1980 елның октябрендә “Коммунизмга” газетасы 50 еллык юбилее уңаеннан һәм намуслы хезмәте өчен ТАССРның Югары Советы Президиумы Мактау грамотасы белән бүләкләнә. Мөхәррир Ренат Таҗиевка “ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре” дигән Мактаулы исем бирелә. Бергә эшләгән Ильяс Фәттахов сөйләгәннәрдән: “80нче еллар тәнкыйть материалларына иң бай еллар. Бик кыю яза идек. Журналист ярдәме белән бик күп проблемалар хәл ителде. Алдынгылар турында күп язылды. Мөхәррир Ренат Таҗиев югары белемле журналист иде. “Без аз, әмма без телняшкадан”, дип әйтергә ярата иде. Ул моряк булган кеше. Райкомның бик көчле вакыты. Газетада тәнкыйть материаллары чыга. Икенче көнне колхоз рәисләре чабып килә. Ул колхоз рәисләрен тынычландырып чыгара иде. Мөхәррир коллективка авырлык китермәде. Бик кешелекле иде. Хатлар бүлеге итеп куябыз

дигәч, миннән дә лаеклырак кешеләр бар, дип каршы төшкән идем, белмисең икән, өйрәтербез, белергә теләмәсәң, мәҗбүр итәрбез, диде. Кызганыч, гомере кыска булды.”

2000 елның декабрендә “Арча хәбәрләре” газетасына 70 еллык юбилей уңаеннан ТРның Матбугат министры Зилә Вәлиева редакциядә озак еллар тырышып эшләгән хезмәткәрләргә ТР Матбугат министрлыгының Мактау грамотасын тапшырды, редакциягә компьютер бүләк итте. Гомере буе редакциядә машинистка булып эшләгән Рузилә Габитова бу зур бүләккә бик лаек иде. Грамоталы, йомшак күңелле, пөхтә, төгәл, журналистларның да хаталарын таба торган андый намуслы машинистка, корректорлар бик сирәк. Хәзер ул лаеклы ялда.

Редакциядә эшләгән елларында “Арча хәбәрләре” газетасы мөхәррире Тәлгать Гомәровка, җаваплы сәркәтип Радик Фәизовка ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре исеме бирелде. Тәлгать Гомәров кызып китеп турысын әйтсә дә, шунда ук суынып, бернәрсә булмагандай елмаеп сөйләшер иде. Ачу сакламады. Юмарт, күңелле кеше. Кыю мәкаләләре белән билгеле мөхәррир. Хәзер лаеклы ялда. Язучы Радик Фәизов районда “Тукай якташлары” түгәрәген алып барды, иҗат итүче яшьләр белән эшләде, аларга акыллы киңәшләрен бирде, үзе матур хикәяләр, повестьлар язды, кешеләр турында язарга яратты, кешегә авыр сүз әйтә белмәде, нечкә күңелле, һәвәскәр балыкчы да иде әле.

2006 елның декабрендә “Арча хәбәрләре” газетасы редакциясе “Энергетика 70+5” республика конкурсында катнашып, җиңү яулый һәм Идел буе электр челтәре “Сетевая компания” филиалы Мактау грамотасы, акчалата премия ала. Журналистлар район электр челтәрендә озак еллар намуслы хезмәт иткән ветераннар турында бик күп мәкаләләр әзерләде, тарихны алар авызыннан сөйләтте.

2008 елда “Арча хәбәрләре” газетасы баш мөхәррире Исрафил Насыйбуллинга медиабазарны оештыруга зур өлеш керткәне өчен ТРның Премьер-министры Р.Н. Миңнеханов Рәхмәт хаты тапшырды. Исрафил Рәхмәтуллович редакциядә реклама эшен тиешле дәрәҗәдә оештырды. Редакциягә ремонт ясалды, эш өчен уңайлы шартлар тудырылды, матди-техник база баетылды.

2011 елның сентябрендә “Арча хәбәрләре” газетасы редакциясе “Авыл. Кеше һәм хезмәт” конкурсында “Иң яхшы район матбугаты” исеменә һәм ТРның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы Дипломына лаек булды. 2012 елда Ильяс Фәттахов конкурста җиңеп, ТР Авыл хужалыгы һәм азык-төлек министрлыгы Дипломын алуга иреште. Авыл хуҗалыгы мөдире Ильяс Фәттахов бик кыю язучы журналист, фельетончы. Авыл хуҗалыгын яхшы белә, урыннардан яңалыкларны, хәбәрләрне алып кайтып тора, гади кешене яклаудан, аның хезмәтен күрсәтүдән тәм таба, кыскасы, авыл хуҗалыгын үстерүгә зур өлеш керткән каләм остасы.

2012 елда журналист Гөлсинә Зәкиева республика күләмендәге “Ышаныч һәм куркынычсызлык” конкурсында җиңү яулап, ТР Эчке эшләр бүлеге дәүләт инспекциясе Дипломы белән бүләкләнде. Гөлсинә энергияле, төрле темага язучы бик өлгер журналист, өч бала әнисе. Кичләрен театр уйнарга да вакыт таба. Йокларга вакыты каламы икән, дип уйлап куясың. Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча даими язып тора. Рейдларга чыга, кызыклы репортажлар яза, өр-яңа хәбәрләр әзерли һәм республика күләмендәге конкурсларда хезмәте бәяләнми калмый.

2013 елның июлендә хатлар бүлеге мөхәррире Румия Надршина югары һөнәри осталыгы һәм озак еллар нәтиҗәле хезмәт иткәне өчен РФ Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнде. Арча кызы Румия яңа оешкан Яңа Чишмә районында эшләп кайткан тәҗрибәле журналист. Бик уйлап яза, аның тормыш лозунгы: иң зур гөнаһ – кешегә начарлык эшләү.

2014, 2015 елларда Румия Надршина, “Фемида—2013”, “Фемида—2014” конкурсларында катнашып, ТРның судьялар Советы Дипломы белән бүләкләнде. Ул судта катнашып, репортаж гына язмады, теманы төрле яклап ачарга тырышты, ничек тә җай табып, гаепленең үзе, якыннары белән сөйләшергә тырышты, җәмәгатьчелек фикерен өйрәнде.

Жюри составында булган “Ватаным Татарстан” газетасы баш мөхәррире Назыйм Сәфәров аның язмаларына югары бәя бирде.

Редакция дивары Мактау грамоталары, Дипломнар белән тулы. Аларның барысын да санап чыгу (30лап бар) мөмкин түгел. (14) [4,5].




## Без – сәяхәтче, артист һәм драматург та әле!

Хезмәттәшебез Гөлсинә Зәкиева үзен талантлы журналист булуы өстенә, драматург буларак та танытты. Соңгы ике–өч елда ул бер–бер артлы алты пьеса язды. Аның “Елый икән, елый ирләр дә” пьесасы Арчада гына түгел, Казанның мәртәбәле театрларында да аншлаг белән узды. Шул пьеса буенча фильм да төшерелде. Бу көннәрдә Арча халык театры Гөлсинә Зәкиеваның “Әни диясем килә” пьесасын сәхнәләштерү өстендә эшли.

Моннан тыш редакция коллективы 2003, 2010 елларда район күләмендә барган иҗат концертларында катнашып, район сәхнәсендә чыгышлар ясады, җиңүләр яулады (15).



Коллективыбыз җәмәгать тормышында, өмәләрдә дә актив катнаша. Агачлар утыртып, “Арча хәбәрләре” газетасы паркы булдырдык, аны даими карап торабыз(16).



Хәйрия акциясе кысаларында Яңа Кенәр интернат–мәктәбенә барып, концерт куйдык, анда тәрбияләнүче балаларга бүләкләр тапшырдык. Ял итүләрне дә күңелле һәм файдалы итеп оештырабыз. Коллектив белән Мәскәүгә, Санкт–Петербургка, Болгарга, Биләргә, Свияжскка бардык, теплоходларда сәяхәткә чыктык (17) [5].



## “Арча хәбәрләре”нең үз кыйбласы бар

### Безнең турыда газета укучыларыбыз

**Синсез булмый**
Заманалар кырыс, акча ягы яман.
Әмма газетабыз чыгып тора һаман.
Язмаларым чыга битләрендә аның.
Мактап язам бит мин авыл уңганнарын.
Авыл уңганнары иртән иртүк тора.
Вакытында чәчә, вакытында ура.
Күпләп мал үрчетә, нәрсәдер юна…
Эштән соң газета тота ул кулына.
Иң элек тотканы районда чыкканы.
Кем генә яратып укымый соң аны!
Кызыксына халык–сөт савулар ничек?
Чучка балалары ятмыйлармы өшеп?
Фураж җитәрлекме? Кем нәрсәләр урлый?
Белеп торыйм дисәң, газетасыз булмый!
“Арча хәбәрләре”н котлыйм чын күңелдән
Зур бәйрәмең белән, юбилееӊ белән!

**Вазыйх Рәхимов, Арча, 2000 ел.**

“СССР да яшәгәндә ил күләмендә барлыгы 50–60 төрле газета–журнал чыга иде. Хәзер бу сан Татарстанда гына да 500гә җитә (“Мәдәни җомга” 11 ноябрь 2005 ел). Уйландыра торган сан. Бу басмалар арасында җиңел темаларга гына мөрәҗәгать итүче, арзанлы популярлык казанырга тырышучылары да бар. Ә безнең “Арча хәбәрләре”нең 75 ел буе үз кыйбласына тугры булып, яулап алган үз урыны, үз йөзе, үз юнәлеше бар”.

**Рәйсә Насретдинова, Яңа Кырлай авылы, 2005 ел.**

“Заман сулышын тоеп, җәмгыять белән бергә атлаган басма гына гомерле була ала. “Арча хәбәрләре” газетасы менә шундый. Ә газетаның язмышы анда эшләгән журналистларга бәйле”.

**Илсум Садыйков, Утар Аты авылы, 2005 ел.**

“75 ел эчендә район газетасында берничә буын сәләтле, принципиаль, журналистика этикасына тап төшермәгән журналистлар эшләде һәм эшли. Газета халыкның иң гадел яклаучысына һәм киңәшчесенә әверелде. Ул Арча халкының гаять зур әһәмияткә ия байлыгы булды һәм булачак ”.

**Алмас Назиров, Арча район хакимияте башлыгы 2005 ел.**

“Район газетасы — иң кирәкле, иң әһәмиятле материалларны туплаган файдалы газета, күркәм эшләрне, хезмәт алдынгыларын яктырткан трибуна, кызыклы яки гыйбрәтле язмышларны чагылдыручы көзге”.

**Зөлфия Ганиуллина, Шушмабаш, 2005 ел** [6].

# Матбугат көчен исбатлыйбыз

**Исәнмесез, “Арча хәбәрләре” хезмәткәрләре!**

17 гыйнварда сезгә үзебезнең үтенечебезне әйтеп (Ашытбаштагы су каланчасы турында), ярдәм итүегезне сорап хат юллаган идек. Хатны алуга ук, сез авылыбызга килеп, бу мәсьәләне хәл итүгә керештегез һәм бик тиз арада уңай хәл итүгә дә ирештегез. Су каланчасына автомат көйләгеч куйдырылды. Нургаян абый да хәзер рәхәтләнеп ял итә, су да агып утырмый, халык та рәхмәт укып бетерә алмый.

“Арча хәбәрләре” газетасының һәр санын көтеп алабыз, һәр мәкаләсен зур кызыксыну белән укыйбыз. Әлеге мәсьәлә бер безне генә кызыксындырмый икән ( 6 февраль чыккан И.Фәттаховның “Алар хезмәте бик җаваплы” мәкаләсе дә шул хакта сөйли). Һәр авылның үз проблемасы. Аларны чишүдә, авылларны саклап калып, яшәтүдә сезнең хезмәтегез аеруча зур. “Хат юлга чакырды” рубрикасын җанландырып җибәрүегез бик файдалы булды.

Халык өчен иң кирәкле су, ут, юл һ.б. мәсьәләләр еш күтәрелә һәм, сезнең ярдәм белән, уңай хәл ителә.

Яраткан газетабыз, син үтә дә җаваплы, кирәкле эш башкарасың. Заман белән бергә атлау, елдан-ел камиллеккә омтылу, халыкны мәгълүматлы итү, аңа һәрвакыт ярдәмгә атлыгып тору, яңалыкның асылына төшенергә булышу –синдәге асыл сыйфатлар. Газетада басылган язмаларыгыз укучылар тарафыннан яратып укыла, авыр чакларында сезгә барып егыла халык. Матбугат көченең зурлыгын тагын бер кабат исбатладыгыз. Сезнең каләм көче киләчәктә дә тутыкмасын. Халык сүзенә игътибарлы карашыгыз, аңа карата хөрмәтегез һөнәри осталыгыгыз турында сөйли. Зур рәхмәт Сезгә!

Хөрмәтле “Арча хәбәрләре” газетасы хезмәткәрләре! Барыгызга да нык сәламәтлек, гаилә бәхете, тыныч, имин көннәр, матур киләчәк һәм яңадан-яңа иҗат уңышлары телибез.

**Хөрмәт белән Ашытбаш авылының Тукай урамы яшьләре**

**9 февраль 2015 ел** [7]

**Быел яз Кече Төрнәле авылының ир–егетләре Казанка аша салынган җәяүлеләр күперен төзекләндерү эшләрен башкарды. Изге гамәл кылуда үз өлешләрен кертүчеләргә Аллаһы Тәгалә әҗер–савапларын бирсен (18).**



Аңарчы үзәккә үткән юлсызлыктан зар–интизар булып, 230 метрлы басманы төзекләндерүне, авылга юл кертүне сорап район хакимиятенә берничә хат язып мөрәҗәгать итеп карасак та, нәтиҗәсе булмады. Узган ел декабрь аенда авыл халкы, шушы мәсьәләдә булышлык сорап, “Арча хәбәрләре” газетасы аша район хакимиятенә хат юллагач, Арча урман хуҗалыгыннан җитәрлек агач бирергә һәм авыл халкының үз көче белән төзекләндерергә, дигән карар чыгарыла. Әле алай гына да түгел, авылга быелгы җәйдән асфальт юл салуны үз эченә алган проект та тормышка ашырылачак.

Район газетасының халык гозерен шундук хәл итәргә тотынуы, халыкның проблемаларын чишүдә район җитәкчелеге белән тыгыз элемтәдә эшләве, ә район башкарма комитеты җитәкчесе Илшат Нуриевның безнең авылны да башка авыллар белән тигез күреп, гозеребезгә игътибар иткәне, ярдәм кулы сузганы өчен чиксез рәхмәтлебез.

**Ихтирам белән Кече Төрнәле авылы халкы**
**29 апрель 2015 ел**

**Газета фатир алып бирде (19)**



1970 елда Казанда киномеханиклар курсын тәмамлап, Арчага эшкә кайттым. 1973 елда өйләндем, ике кызыбыз туды. Ул вакытта чиркәү бинасында кинопрокат урнашкан иде. Чиркәү капкасы янында элек каравылчы торган 1 метр калынлыктагы стеналы, 12 квадрат метрлы бинаны фатир итеп бирделәр. 1983 елга кадәр шунда газап чиктек. Балалар үскән саен хәл катлаулана барды, кызлар йокыга киткәнче төн уртасына кадәр урамда йөри идем.

Үзебезнең хәлне аңлатырга тырышып, төрле оешмалар ишеге төбен таптадым, аңларга, булышырга теләүчеләр табылмады. Соңгы өмет белән район газетасы редакциясенә мөрәҗәгать иттем. Хатлар бүлеге мөдире Ильяс Фәттахов безнең хәлне үзе килеп күрде, күргәннәрен газетада язып чыкты. Озак та үтмәде, безгә ике бүлмәле фатир бирделәр, куанычыбызның чиге булмады.

Бүгенге көндә хатыным да, үзем дә лаеклы ялда. Биш оныгыбыз бар. Район газетасы безнең гаилә өчен бик кадерле.

**Мәсхүт Ногманов, хезмәт ветераны.**
**Арча шәһәре.**
**29 апрель 2015 ел**

Шактый еллар үтсә дә, мин бу вакыйганы яхшы хәтерлим. Әлеге гаиләнең нинди шартларда яшәвен күреп бик тетрәнгән идем. Тәнкыйть — конфет түгел, ул вакытта да аны югарыдагылар өнәп бетермиләр иде. Партиянең куәтле еллары иде бит. Әмма газета сүзе белән алар да исәпләшергә мәҗбүр иде. Мин язганны яратып бетермәсәләр дә, фатирны бирделәр. Ногмановлар гаиләләре белән килеп рәхмәт әйтеп киттеләр. Бу турыда уйласам, әле дә күңелгә рәхәт булып китә.

**Ильяс Фәттахов** [7].

## Мәгълүмат чыганаклары исемлеге:


1. ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе.
2. “Бөек Тукай Ватаны, син Арча” китабы.
3. Редакциядә эшләп киткән шәхесләрнең истәлекләре.
4. “Арча хәбәрләре” газетасы редакциясе архивы.
5. Редакция хезмәткәрләренең шәхси архивлары.
6. “Арча хәбәрләре” газетасы төпләнмәләре.
7. http://arskmedia.com